РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38

тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38

тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 04 » 03 2025 г. №202

2025 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чаралары турында

"Янгын куркынычсызлыгы турында"гы 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ санлы Федераль законның 18 статьясы, «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында»гы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 санлы карары белән расланган Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләренең 417 пункты, «2025 елда Татарстан Республикасында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чаралары турында»гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 13 февралендәге 81 санлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән превентив чараларны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар итте:

1. 2025 елның 1 апреленнән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә янгын куркынычы сезоны башлануын билгеләргә.

2. Тәкъдим итәргә:

Ютазы муниципаль районының авыл җирлекләре башлыкларына янгын куркынычы сезоны башланганчы:

- «Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында»гы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 санлы карары белән расланган Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләренең XX бүлеге нигезендә урман янгыннары һәм башка ландшафт (табигый) янгыннар куркынычы янаган торак пунктларны үз вәкаләтләре чикләрендә паспортлаштыруны тәэмин итәргә;

- түбәндәге чараларны гамәлгә ашырырга:

торак пунктлар тирәсендә урман янгыннары һәм башка ландшафт (табигый) янгыннары куркынычы янаган, киңлеге кимендә 10 метр булган минераллаштырылган яклау полосалары булдыруга;

урман янәшәсендәге территорияне урманнан кимендә 10 метр киңлектәге полосада коры үлән үсемлекләреннән, камыл калдыкларыннан, ауган агачлардан,

кисү калдыкларыннан, чүп-чардан һәм башка янучан материаллардан чистарту йә урманны кимендә 1,4 метр киңлектәге янгынга каршы минераллаштырылган полоса яисә башка янгынга каршы барьер белән аерып алу;

торак пунктларның гомуми файдаланудагы җирләрендә чүп-чар, үлән, яфраклар һәм башка калдыкларны, материалларны яисә эшләнмәләрне яндыру өчен урыннар бүлеп бирү һәм аларны җиһазлау;

торак пунктларны телефон элемтәсе һәм янгын турында тавыш белән хәбәр итү чаралары белән тәэмин итүгә;

янгын сүндерү максатларында су чыганакларын җиһазлау;

янгыннан ирекле саклау бүлекчәләре әгъзаларының тәүлек буе кизү торуын оештыру.

"Ютазы муниципаль районының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге" МКУ башлыгына:

- «Дубравушка» балаларны савыктыру лагеренда янгын куркынычы сезонында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар күрергә;

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында»гы 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 санлы карары белән расланган Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләренең XX бүлеге нигезендә үз вәкаләтләре чикләрендә урман янгыннары куркынычы янаган «Дубравушка» балаларны савыктыру лагерен паспортлаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

А.Н.Захаров
8(85593)2-42-07